**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5720**
**05.09.2024**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитет Карарлары үз көчен югалткан дип таныrга:

1) 2020 елның 10 апрелендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2020 елның 10 апрелендә «Челнинские известия» газетасының 27 санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 7 апрелендәге 1728 номерлы;

2) 2020 елның 18 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 85 санында бастырып чыгарылган «Башкарма комитетның 2020 елның 7 апрелендәге 1728 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 13 ноябрендәге 5996 номерлы.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 5 сентябрендәге
5720 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмә «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы Боерыгы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы нигезендә эшләнде һәм гражданнар оборонасын алып баруга әзерлекнең һәм алып баруның төп юнәлешләрен, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә (алга таба – Яр Чаллы шәһәре) гражданнар оборонасы буенча төп чараларны билгели.

2. Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасы белән җитәкчелек итү Башкарма комитет Җитәкчесенә (алга таба – Гражданнар оборонасы Җитәкчесе) йөкләнә.

Гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару максатында гражданнар оборонасы Җитәкчесе боерыклар чыгара. Гражданнар оборонасы Җитәкчесенең гражданнар оборонасы өлкәсендә үз компетенциясе чикләрендә чыгарылган боерыклары Яр Чаллы шәһәренең барлык вазыйфаи затлары һәм гражданнары тарафыннан үтәлергә тиеш.

3. Гражданнар оборонасы Җитәкчесе гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында гражданнар оборонасы көчләре, чаралары, объектлары, матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запаслары булдыра һәм туплый, гражданнар оборонасы чараларын планлаштыра һәм гамәлгә ашыра.

4. Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының (алга таба – Башкарма комитет) Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчәсе булып Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе тора.

2 бүлек. Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм алып бару

5. Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыга торган куркынычлардан, шулайук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда Яр Чаллы шәһәре халкын, матди һәм мәдәни кыйммәтләрен саклауга әзерлек чараларын алдан ук

үтәүдән гыйбарәт һәм Яр Чаллы шәһәрендә гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү мәсьәләләре буенча төп чараларны күздә тоткан еллык план (алга таба – төп чаралар планы) нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Гражданнар оборонасын алып бару Яр Чаллы шәһәренең гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау планы нигезендә гамәлгә ашырыла, анда сугыш вакытында гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чаралар күләме, аларны оештыру, тәэмин итү тәртибе, үтәү ысуллары һәм сроклары билгеләнгән.

7. Еллык төп чаралар планы Башкарма комитет тарафыннан эшләнә һәм гражданнар оборонасы бурычларын һәм Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бурычларны хәл итәргә вәкаләтле орган – Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе белән килештерелә.

8. Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм алып бару буенча төп чараларны планлаштыру, хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук булуы ихтимал террорчылык актлары һәм, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә, Яр Чаллы шәһәре территориясендә килеп чыгарга мөмкин булган хәлләрне һәрьяклап бәяләүне исәпкә алып башкарыла.

9. Башкарма комитет карары нигезендә, оештыру һәм эшчәнлек тәртибе аларны булдырган орган тарафыннан коткару хезмәтләре турында тиешле нигезләмәләрдә билгеләнә торган коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре): медицина, инженерлык, коммуналь-техник, янгынга каршы, җәмәгать тәртибен саклау, хәбәр итү һәм элемтә, мәдәни кыйммәтләрне саклау, автотранспорт, сәүдә һәм туклану һәм башкалар булдырыла.

Яр Чаллы шәһәренең коткару хезмәте составына гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү, авария-коткару формированиеләренең эш итүләрен һәрьяклап тәэмин итү һәм хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетергәндә башка кичектергесез эшләр башкару өчен билгеләнгән идарә органнары, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары керә.

Коткару хезмәтләренең төре һәм саны гражданнар оборонасы планы һәм халыкны саклау планы нигезендә башкарыла торган бурычларның күләмен һәм характерын исәпләү нигезендә билгеләнә.

Яр Чаллы шәһәренең коткару хезмәте турында нигезләмә тиешле коткару хезмәте җитәкчесе тарафыннан эшләнә, Россия ГТХМ Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (Татарстан Республикасы ГТХМ Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе, Башкарма комитетының гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсе) белән килештерелә һәм гражданнар оборонасы Җитәкчесе тарафыннан раслана.

Яр Чаллы шәһәрендә гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыруга һәм аларның әзерлеген тәэмин итүгә методик җитәкчелек, шулай ук әлеге өлкәдә контроль Татарстан Республикасы ГТХМ Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсе һәм Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10. Эвакуация чараларын планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү өчен алдан ук, тыныч вакытта, шәһәрнең эвакуация комиссиясе төзелә. Эвакуация комиссиясе Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарларының берсе тарафыннан җитәкчелек ителә. Эвакуация комиссиясе эшчәнлеге Башкарма комитет тарафыннан расланган эвакуация комиссиясе турында нигезләмә белән регламентлаштырыла.

11. Тыныч вакытта, коткару хезмәтләренең көчләре табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чараларда катнашу өчен җәлеп ителергә мөмкин.

Тыныч вакытта, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен, коткару хезмәтләре көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында карарны гражданнар оборонасы Җитәкчесе кабул итә.

12. Гражданнар оборонасы буенча чараларны оештыруны һәм планлы рәвештә гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шул исәптән тыныч вакытта һәм сугыш вакытында фаразлана торган һәм барлыкка килгән куркынычлар турында халыкка үз вакытында хәбәр итү максатында, Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат  (алга таба – мәгълүмат) җыю һәм алмашу оештырыла.

13. Мәгълүмат җыю һәм алмашу Башкарма комитет, шулай ук билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән һәм куркынычлылык буенча I һәм II класслы куркыныч җитештерү объектларын, аеруча радиацион куркыныч һәм атом-төш куркыныч производстволарны һәм объектларны һәм югары куркынычлылык дәрәҗәсендәге гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүче оешмалар, шулай ук билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, оешмалар – Башкарма комитетка тапшыра.

## 3 бүлек. Гражданнар оборонасы буенча чаралар

14. Гражданнар оборонасы буенча чаралар Яр Чаллы шәһәрендә гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм алып бару кысаларында оештырыла.

15. Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатында, Башкарма комитет түбәндәге төп чараларны планлаштыра һәм гамәлгә ашыра:

1) халыкны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү буенча (Татарстан Республикасы ГТХМ Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча идарәсе ярдәме белән Башкарма комитетка йөкләнгән (килешү буенча):

- шәһәр халкын хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыга торган куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда саклану ысулларына әзерләү һәм оештыру;

- шәһәр формированиеләренең һәм хезмәтләренең шәхси составын әзерләү;

- гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм тренировкалар үткәрү;

- шәһәр территориясендә урнашкан оешмалар формированиеләренең һәм хезмәтләренең шәхси составын, хезмәткәрләрен әзерләүне оештыру-методик җитәкчелек итү һәм контрольдә тоту;

- гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктларын булдыру, җиһазландыру һәм аларның эшчәнлеген оештыру;

- гражданнар оборонасы өлкәсендә белемнәрне пропагандалау;

2) хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә килеп чыга торган куркынычлар турында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда халыкка хәбәр итү буенча (Татарстан Республикасы ГТХМ Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсенең оештыру-методик ярдәме белән элемтә һәм хәбәр итү буенча коткару хезмәтенә йөкләнгән):

- халыкка хәбәр итү буенча локаль системалар булдыру, реконструкцияләү һәм файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту;

- кешеләр күпләп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү буенча махсуслаштырылган техник чаралар урнаштыру;

- бердәм электр элемтәсе челтәре, радио-, чыбыклы һәм телевизион тапшырулар чараларыннан һәм мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларыннан комплекслы файдалану;

- гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу;

3) халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү буенча (Башкарма комитетка йөкләнгән):

- халыкны, материаль һәм мәдәни кыйммәтләрне куркыныч янау ихтималы булган зоналардан куркынычсыз районнарга эвакуацияләү буенча чараларны планлаштыру, әзерләү һәм үткәрүне оештыру, шулай ук сугыш вакытында үз эшчәнлеген дәвам итүче оешма хезмәткәрләрен һәм куркыныч янау ихтималы булган зоналарда гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешма хезмәткәрләрен таратып урнаштыруны оештыру;

- эвакуацияләнергә тиешле халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне урнаштыру өчен куркынычсыз районнар әзерләү;

- эвакуация органнары булдыру һәм эшчәнлеген оештыру, шулай ук аларның шәхси составын әзерләү;

4) халыкка индивидуаль һәм коллектив саклау чаралары бирү буенча (коммуналь-техник коткару хезмәтенә йөкләнгән):

- гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм аларның техник системаларын төзү, саклау, билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту һәм техник хезмәт күрсәтү;

- тыныч вакытта, гражданнар оборонасын алып баруга әзерләгәндә һәм сугыш вакытында аны алып бару барышында, җир асты киңлегенең тирәндә урнашкан бүлмәләрен һәм башка корылмаларын халыкны качырып тору өчен җайлаштыру;

- тыныч вакытта гражданнар оборонасының тиз төзелә торган, гадиләштерелгән эчке җиһазлары булган саклау корылмаларын һәм гади типтагы ышыклану урыннарын әзерләү һәм гражданнар оборонасын алып баруга әзерләгәндә һәм сугыш вакытында аны алып бару барышында төзү;

- гражданнар оборонасының саклау корылмаларында, җир асты киңлегенең тирәндә урнашкан бүлмәләрендә һәм башка корылмаларында халыкны качырып торуны тәэмин итү;

- индивидуаль саклау чараларын туплау, саклау, яңарту һәм билгеләнеше буенча файдалану;

- билгеләнгән срокларда халыкка индивидуаль саклану чараларын бирүне һәм коллектив саклау чараларын бирүне тәэмин итү;

5) яктылык маскировкасы һәм аның башка төрләре буенча (энергия белән тәэмин итү буенча коткару хезмәтенә йөкләнгән):

- маскировкаланырга тиешле объектлар исемлеген билгеләү;

- шәһәр территориясен комплекслы маскировкалауны гамәлгә ашыру планын эшләү;

- билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән оешмалар тарафыннан яктылык маскировкасы һәм маскировкалауның башка төрләре буенча чаралар үткәрү өчен кирәкле матди-техник чаралар запасларын булдыру һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту;

- билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән оешмалар тарафыннан демаскировкалау билгеләрен киметү буенча инженерлык-техник чаралар үткәрү;

6) хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә халык өчен куркынычлар барлыкка килгән очракта, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү буенча (Яр Чаллы шәһәренең оешмалар җитәкчеләренә (гражданнар

оборонасы Җитәкчесенә) йөкләнгән, үтәлешне тәэмин итү Башкарма комитетка йөкләнгән):

- авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү өчен кирәкле гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыру, җиһазландыру һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;

- авария-коткару эшләрен һәрьяклап тәэмин итү өчен матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту;

7) хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халык яшәешен беренче чиратта тәэмин итү, (түбәндәге коткару хезмәтләренә йөкләнгән: коммуналь-техник, сәүдә һәм туклану, медицина, инженерлык):

- халык яшәешен беренче чиратта тәэмин итүнең төп төрләрен планлаштыру һәм оештыру;

- матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлектә тоту;

- халыкны азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән нормалаштырылган тәэмин итү;

- халыкка коммуналь-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү;

- зыян күргән халык арасында санитария-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

- зыян күрүчеләрне дәвалау учреждениеләренә эвакуацияләүне гамәлгә ашыру;

- тораксыз калган халык санын билгеләү;

- сакланып калган торак фондын инвентаризацияләү һәм зыян күргән торак фондының торышын бәяләү, аны зыян күргән халыкны урнаштыру өчен файдалану мөмкинлеген билгеләү, тораксыз калган кешеләрне ял йортларында, пансионатларда һәм башка сәламәтләндерү учреждениеләрендә, вакытлыча торакларда (җыелма йортларда, палаткаларда, землянкаларда һ. б.) урнаштыру, шулай ук халыкны сакланып калган торак фонды мәйданына урнаштыруны гамәлгә ашыру;

- халыкка мәгълүмати-психологик ярдәм күрсәтү;

8) хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән янгыннарга каршы көрәш буенча (гамәлдәге законнар белән билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында ТР буенча РФ ГТХМ Баш идарәсе Күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә һәм ТР буенча Россия ГТХМ ДУ Дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтнең 15 нче янгын-коткару отрядына йөкләнгән (килешү буенча):

- янгынга каршы кирәкле көчләр булдыру, аларны матди-техник чаралар белән җиһазландыру һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

- сугыш вакытында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү районнарында янгыннарны сүндерү;

- сугыш вакытында, билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән объектларда янгыннарны сүндерү;

9) радиоактив, химик, биологик яки башка зарарлануга дучар булган районнарны ачыклау һәм билгеләү буенча (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы Кама буе территориаль идарәсе ярдәме белән Башкарма комитетка йөкләнгән (килешү буенча):

- гражданнар оборонасын күзәтү һәм лаборатор контрольдә тоту һәм халыкны саклау челтәрен – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының гамәлдәге махсуслаштырылган учреждениеләрен, бүлекчәләрен һәм хезмәтләрен һәм Татарстан Республикасы территориясендә радиацион, химик, биологик хәлләрне

күзәтү һәм контрольдә тоту функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмаларны булдыру һәм әзерлеген тәэмин итү;

- радиоактив зарарлануга (пычрануга) дучар булган территорияләрдә радиациядән саклау режимнары кертү;

- радиацион, химик, биологик хәлне, шул исәптән азык-төлек һәм әйләнә-тирә мохит объектларының радиоактив, химик һәм биологик матдәләр белән зарарлану (пычрану) дәрәҗәсен мониторинглау методларын һәм техник чараларын камилләштерү;

10) халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү буенча (санитария-эпидемиология хезмәтенә йөкләнгән):

- дезактивация, дегазация һәм дезинфекция матдәләре һәм эремәләре запасларын алдан ук булдыру;

- халыкны санитар эшкәртү һәм техниканы, биналарны һәм территорияләрне зарарсызландыру өчен гражданнар оборонасы көчләрен булдыру, шулай ук аларны җиһазландыру һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

- техниканы, биналарны һәм территорияләрне зарарсызландыру, халыкны санитар эшкәртү буенча чаралар үткәрүне оештыру;

11) хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән шәһәрдә тәртип булдыру һәм саклау буенча (Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсенә йөкләнгән):

- җәмәгать тәртибен саклау көчләрен булдыру, аларны матди-техник чаралар белән җиһазландыру һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

- җәмәгать тәртибен булдыру һәм саклау, шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларда халыкны эвакуацияләү һәм гражданнар оборонасы көчләренең хәрәкәт итү маршрутларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

- Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны саклауны көчәйтү, караучысыз калган мөлкәтне саклау буенча чаралар күрү;

12) сугыш вакытында кирәкле коммуналь хезмәтләрнең эшчәнлеген тиз арада торгызу мәсьәләләре буенча (коммуналь-техник хезмәткә йөкләнгән):

- коммуналь хезмәтләрнең сугыш вакыты шартларында эшләргә әзерлеген тәэмин итү һәм аларның эш итүләрен планлаштыру;

- зыян килгән газ, энергия, су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау өчен җиһазлар һәм запас частьләр запасларын булдыру;

- суны чистарту, төчеләндерү һәм транспортлау өчен мобиль чаралар резервын булдыру һәм әзерләү;

- су үткәрү станцияләрендә реагентлар, реактивлар, консервантлар һәм дезинфекция чараларының кирәкле запасларын булдыру;

- резервуарлар һәм сыешлыклар, җыела-сүтелә торган үткәргеч торбалар, мобиль резерв һәм автоном энергия чыганаклары, башка кирәкле җиһазлар һәм техник чаралар запасларын булдыру;

13) сугыш вакытында мәетләрне тиз арада күмү буенча (коммуналь-техник хезмәткә йөкләнгән):

- алдан ук, күмәргә мөмкин булган урыннарны билгеләү;

- мәетләрне тиз арада күмү чараларын тәэмин итү өчен, шул исәптән махсуслаштырылган ритуаль оешмалар базасында гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыру, әзерләү һәм әзерлектә тоту;

- законнарда билгеләнгән кагыйдәләрне үтәп, мәетләрне тану, исәпкә алу һәм җирләү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү;

- санитар-эпидемиологик күзәтчелекне оештыру;

14) хәрби конфликтларда яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын тәэмин итү буенча (сәүдә һәм туклану буенча коткару хезмәтенә йөкләнгән):

- икътисад объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча комиссия төзү һәм тыныч вакытта һәм сугыш вакытында эшен оештыру;

- төзелеш нормалары һәм гражданнар оборонасының инженерлык-техник чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләре таләпләренә туры китереп, икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук җитештерү чараларын рациональ урнаштыру;

- газ, энергия һәм су белән тәэмин итү системалары һәм чыганаклары эшчәнлегенең ышанычлылыгын арттыруга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм үткәрү;

- гражданнар оборонасының инженерлык-техник чараларын эшләү һәм тыныч вакытта һәм сугыш вакытында тормышка ашыру;

- сугыш вакытында эшне дәвам итүче икътисад объектларында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү;

- җитештерү процессын саклау һәм (яки) торгызу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын алдан ук булдыру;

- документларның иминият фондын булдыру;

- аларга заманча зарарландыру чаралары тәэсир иткәндә, җитештерү фондларын саклау нәтиҗәлелеген арттыру;

15) гражданнар оборонасы көчләренең һәм чараларының даими әзерлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча (Башкарма комитетка йөкләнгән):

- гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм заманча техник чаралар белән тәэмин итү;

- гражданнар оборонасы көчләрен әзерләү, гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм тренировкалар үткәрү;

- гражданнар оборонасы көчләренең гамәлләрен планлаштыру;

- авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне үткәрү өчен югары нәтиҗәле технологияләр эшләү;

- үзара хезмәттәшлек тәртибен билгеләү һәм гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү, шулай ук аларның эш итүләрен һәрьяклап тәэмин итү.

16. Яр Чаллы шәһәрендә гражданнар оборонасы буенча чараларны финанслау Яр Чаллы шәһәре бюджетында каралган акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева